**СОВЕТ МАЛОЕЛГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**422619 с. Малая Елга**
**тел: 8-(84378) -3-25-16**
**факс: 8-(84378) -3-25-16**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ ЕЛГА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**422619 Кече Елга авылы**
**тел: 8-(84378) -3-25-16**
**факс: 8-(84378) -3-25-16**

**2025 елның «05» марты** **4 номер**

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Кече Елга авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 12 декабрендәге 50 номерлы Кече Елга авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Кече Елга авыл җирлеге советы карар кабул итте.**:**

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Кече Елга авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 12 декабрендәге 50 номерлы Кече Елга авыл җирлеге карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1) **9 статьяның 5 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

5. «Россия Федерациясе субъектларының (муниципаль берәмлекләрнең) финанс органнары Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актында билгеләнгән очракларда һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә әлеге Кодексның 242_26 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән акчаларны киңәйтелгән казначылык озатып йөрүен гамәлгә ашырырга хокуклы»;

2) **11 статьяның 5 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

5. «Муниципаль контрактлар муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар план-графигы нигезендә, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә төзелгән һәм расланган тәртиптә төзелә(Россия Федерациясе законнары нигезендә тиешле сатып алу мондый план-графикка кертелмәскә тиеш очраклардан тыш) һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә түләнә, моңа әлеге статьяның 3 пунктында билгеләнгән очраклар керми»;

3) **27 статьяның 3 пунктына** түбәндәге эчтәлекле яңа абзац өстәргә:

"бюджет ассигнованиеләре ашыгыч гуманитар җавап бирү, гуманитар ярдәм йөкләрен китерү, халыкны эвакуацияләү, гадәттән тыш хәлләрне бетерү чараларын финанс белән тәэмин итүгә яңадан бүленгән очракта";

4) **36 статьяның 2 пунктында** «беренче биш эш көнендә» сүзләрен «бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча» сүзләренә алмаштырырга**.**;

5) **9 статьяның 28 пунктындагы 1 пунктчасының 6 абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“РФ БК 242_26 статьясының 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә билгеләнгән акчаларны казначылык озата баруы, РФ БК 242_23 статьясындагы 5 пункты нигезендә яисә РФ БК 242_23 статьясындагы 3 пункты нигезендә Федераль казначылык тарафыннан РФ БК 220_2 статьясы нигезендә Россия Федерациясе субъектының (муниципаль берәмлекнең) финанс органының аерым функцияләрен башкарганда, Россия Федерациясе субъектының (муниципаль берәмлекнең) финанс органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.”

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Кече Елга авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Кече Елга җирлеге Советының план-бюджет һәм икътисадый үсеш комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Кече Елга**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **Р.З. Хисамов**